| | |
|---|---|
| **ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10.11.2021 ел.** **Мәлки авылы** **№ 3**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Кыр Буасы авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Кыр Буасы авылы, Үзәк урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан Кыр Буасы авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.**

2. 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Кыр Буасы авылы, Үзәк урамы, 21 нче йорт адресы янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә**.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Буа чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- су башнясын һәм суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау һәм реконструкцияләү, Кыр Буасы авылында материаллар сатып алу;

- су алу скважиналарын (каптажларны)лицензияләү буенча әзерлек эшләре;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту .»;

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә Мәлки авыл җирлеге территориясендә Яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге башлыгы Ф.П.Поляков